# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

2025 елда Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Әсәй авыл җирлеге Әсәй торак пунктында гражданнарның үзара салымын кертү турында

**№ 2** **13 ноябрь 2024 ел.**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Әсәй авыл җирлеге Әсәй торак пунктында гражданнар җыены карар кабул итте:

2025 елда Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Әсәй авыл җирлеге Әсәй торак пунктында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 400 сум күләмендә, 1 төркем инвалидлардан, Бөек Ватан сугышы ветераннарыннан һәм катнашучылардан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарыннан, көндезге уку формасында белем алучы студентлардан, мобилизация буенча чакырылган гражданнар һәм аларның гаилә әгъзаларыннан, хәрби хезмәт узу турында контракт төзегән һәм махсус хәрби операциягә җибәрелгәннәрдән тыш, үзара салым кертүгә һәм түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә ризамы:

1.Урамнарны тышкы яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар астындагы мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җайланмаларны (лампалар, яктырткычлар, электр товарлары һәм махсус җайланмалар сатып алу һәм алыштыру, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Әсәй торак пунктында урамнарны яктыртуны ремонтлау һәм аларга хезмәт күрсәткән өчен муниципаль контракт буенча түләү);

2. Торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмиятле автомобиль юлларын төзү, ремонтлау

- (Әсәй торак пунктында Үзәк, Нарат, Мәктәп, Ясле, Тау асты урамнары буенча авыл эчендәге юлларны ремонтлау (вак таш түшәлгән юлларны төзү һәм ремонтлау, вак таш сатып алу, ташу, муниципаль контракт буенча эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү) ;

- (Әсәй торак пунктында юлларны кардан чистарту, муниципаль контракт буенча эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү)

3. Әлеге карарны түбәндәге адрес буенча урнашкан мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән игълан итәргә:

- Азнакай районы, Әсәй авылы, Үзәк урам, 38Б йорт,
- Азнакай районы, Әсәй авылы, Үзәк урамы, 60 йорт.
- Азнакай районы, Әсәй авылы, Елга Аръягы урамы., 27 йорт.
- әлеге карарны, кабул ителгән көннән алып 10 көн эчендә, Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Интернет "мәгълүмат-коммуникацион челтәрендә түбәндәге веб-адрес буенча» урнаштырырга: http://aznakaevo.tatarstan.ru., Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында түбәндәге веб-адрес буенча бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru

Азнакай муниципаль районының
халык җыенында рәислек итүче,
Әсәй авыл җирлегенең Башлыгы Г.З. Дәминова